МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

14.06.2019 Казан ш. № 11-66

"Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәне раслау хакында" 11.08.2016 ел, №11-96 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Б о е р ы к б и р ә м:

"Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәне раслау хакында" 11.08.2016 ел, №11-96 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә кертелә торган үзгәрешләрне (кушымта итеп бирелә) расларга:

Министр Р.Р. Гайзатуллин

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 14.06.2019 ел, №11-66 боерыгы белән расланды

“Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәне раслау хакында” 11.08.2016 ел, №11-96 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә кертелә торган үзгәрешләр

1. 1.2 пунктка “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланыла торган Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый советны оештыру тәртибе нигезендә” дигән сүзләрне өстәргә.

2. 2.1 пунктның дүртенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга.

3. 2.2 пунктка түбәндәге эчтәлектәге абзацны өстәргә:

“җәмгыятьтә коррупцион күренешләргә карата нәфрәт тудыру.”

4. 3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Иҗтимагый совет составы

3.1. Иҗтимагый совет составы, 5 кешедән, ихтыяри катнашу нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланыла торган Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый советны оештыру тәртибе нигезендә булдырыла.

3.2. Министрлык, Иҗтимагый совет составы расланганннан соң 30 көннән дә соңга калмыйча, Иҗтимагый советның беренче утырышын үткәрүне оештыра, анда аның әгъзалары арасыннан Иҗтимагый совет рәисе һәм рәисе урынбасары сайлана. Карар, ачык тавыш бирү юлы белән, Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

3.3. Иҗтимагый совет рәисен яки рәисе урынбасарын вазифасыннан азат итү турында мәсьәлә Татарстан Республикасы финанс министры мөрәҗәгате белән, шулай ук Иҗтимагый совет рәисенең яки рәис урынбасарының шәхсән гаризасы яисә Иҗтимагый совет әгъзалары төркеменең тәкъдиме буенча Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми саныннан кимендә биштән бер өлешен тәшкил иткән әгъзалары тарафыннан карап тикшерелә. Карар Иҗтимагый совет әгъзаларының гомуми саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

3.4. Иҗтимагый совет Рәисе Иҗтимагый совет әгъзалары арасыннан Иҗтимагый советның җаваплы секретарен билгели.

3.5. Иҗтимагый совет әгъзаларының вәкаләтләре срогы яңа булдырылган составтагы Иҗтимагый советның беренче утырышы үткәрелгәннән соң өч ел тәшкил итә.

3.6. Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләре түбәндәге очракларда Иҗтимагый совет рәисе танытмасы буенча, Министрлык боерыгы нигезендә туктатып торыла:

аңа Россия Федерациясе җинаять-процессуаль законы нигезендә билгеләнгән тәртиптә, җинаять кылуда гаепләү белдерелгәндә;

аңа административ кулга алу рәвешендә административ җәза билгеләнгәндә;

ул кандидат сыйфатында дәүләт хакимиятенең законнар чыгару (вәкиллекле) органына депутатлыкка кандидат, җирле үзидарә органында сайланылулы вазифага кандидат, сәяси партия кандидатының ышанычлысы яисә вәкаләтле вәкиле сыйфатында теркәлгәндә, шулай ук ул Россия Федерациясендә референдум үткәрү буенча инициатив төркем составына кергән очракта.

3.7. Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләре түбәндәге очракларда туктатыла:

вәкаләтләре срогы чыккач;

ул Иҗтимагый совет составыннан чыгу турында гариза тапшырганда;

ул сәламәтлеге какшап китү сәбәпле Иҗтимагый совет утырышында катнаша алмаганда;

аңа карата суд тарафыннан чыгарылган гаепләү хөкеме законлы көченә кергәндә;

аны законлы көченә кергән суд карары нигезендә эшкә сәләтсез яки хәбәрсез каядыр киткән дип таныган очракта;

аның тарафыннан этика нормалары тупас бозылганда – утырышта катнашкан Иҗтимагый совет әгъзалары саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителгән Иҗтимагый совет карары буенча;

Иҗтимагый совет утырышлары эшендә нигезле сәбәпсез системалы төстә (өч тапкырдан күбрәк) катнашмаганда;

Иҗтимагый совет рәисе яки рәисе урынбасары кушканны нигезле сәбәпсез системалы төстә (ике тапкырдан күбрәк) үтәмәгәндә;

аны Россия Федерациясе дәүләт вазифасына, Россия Федерациясе дәүләти гражданлык вазифасына, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе башка субъектларының дәүләт вазифасына, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе башка субъектларының дәүләти гражданлык вазифасына, муниципаль вазифага яки муниципаль хезмәт вазифасына билгеләгәндә;

ул чит дәүләт гражданлыгын (подданство) алганда;

Россия Федерациясенең гражданины булудан туктаган очракта.

3.8. Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен туктату, Министрлык боерыгы нигезендә, Иҗтимагый совет әгъзасының язмача гаризасы яки Иҗтимагый совет рәисе яисә Иҗтимагый совет рәисе урынбасары танытмасы буенча, шулай ук бу Нигезләмәнең 3.7 пунктында күздә тотылган хәлләр ачыкланган очракта хәл ителә.

Иҗтимагый совет әгъзасы бу Нигезләмәнең 3.7 пунктындагы дүртенче, бишенче, унынчы-уникенче абзацларында күздә тотылган хәлләрнең килеп чыгуы турында Иҗтимагый совет рәисенә яки рәис урынбасарына хәбәр итәргә тиеш.”

5. 5.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.12. Иҗтимагый совет карары буенча Иҗтимагый совет утырышларына, Иҗтимагый совет тарафыннан карап тикшерелә торган мәсьәләләр буенча кирәкле

мәгълүматлар һәм бәяләмәләр тапшыру өчен, башкарма органнар, коммерциясез оешмалар, фәнни учреждениеләр, экспертлар, башка белгечләр һәм гражданнар чакырылырга мөмкин.».

6. Түбәндәге эчтәлектәге 5.12[1] пунктны өстәргә:

«5.12[1]. Иҗтимагый совет Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзалары эшендә катнашуны тәэмин итә.».

7. 5.14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.14. Иҗтимагый совет эшчәнлегендә оештыру-техник эшләрен Министрлык хәл итә.».